**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального района**
**Республики Татарстан**
**Совет города Арск**
**422000,г. Арск, площадь Советская , 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Арча шәһәр Советы**
**карары**

**«_07_ » июнь 2022 ел** **№ __70_**

**«Җир салымы турында» Арча шәһәр Советының 2017 елның 27 октябрендәге 74 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (21.08.2019 ел, № 124, 19.11.2019 ел, №135 үзгәрешләр белән)**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 31 бүлеге, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советы Уставы нигезендә Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» Арча шәһәр Советының 2017 елның 27 октябрендәге 74 номерлы карарына (21.08.2019 ел, № 124, 19.11.2019 ел, №135 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның пунктын түбәндәге эчтәлектәге 3.1.4, 3.1.5. пунктчалары белән тулыландырырга:

«3.1.4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә аккредитацияләнгән индустриаль (сәнәгать) парклар һәм индустриаль (сәнәгать) парклары резидентларына.

3.1.5. Әфганстан Республикасында һәм хәрби гамәлләр алып барылган башка илләрдә интернациональ бурычларын үтәгән гражданнарга".

1.2. Әлеге карарның 3.1.4. пунктчасы 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалта дип билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1.пунктының 1.1. пунктчасы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

"Арча шәһәре" муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе

«Совет города Арск»

И.Г. Нуриев